ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.06.2020 г. Заинск № 245

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында»**

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы (2020 елның 27 ноябрендәге ПУ-27 редакциясендә), «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру буенча чараларны һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

2. Оештыру-хокукый рәвешләренә бәйсез рәвештә, Зәй муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китереп әзерләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә.

3.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының

оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http//zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И. Ф. Хафизов**

Е.А. Иванова
6-78-04